# Чишмә башы

3 нче сан, гыйнвар

Хәсәншәех балалар бакчасы






*2025 ел – Ватанны саклаучылар елы.*

***Россия Президенты Владимир Путин гаиләләргә ярдәм мәсьәләләре буенча Дәүләт Советында шундый тәкъдим белән чыгыш ясады. Яңа ел тематикасын президент махсус операциядә катнашучылар хөрмәтенә һәм ата-бабаларның батырлыклары истәлегенә сайларга тәкъдим итте. Ел тематикасы хәзерге Россиянең өстенлекләрен чагылдыра – патриотлык, буыннар дәвамчанлыгы һәм Ватанны саклаучыларга хөрмәт. Шунысы игътибарга лаек, Ватанны саклаучылар елы 2024 елда Гаилә елына алмашка килә, һәм бу очраклы түгел. Бу гаилә кыйммәтләре һәм Ватанга героик хезмәт арасындагы тирән бәйләнешне ассызыклый. Демография һәм аналарга ярдәм итү мәсьәләләренә багышланган Гаилә елы киләчәккә нигез салды. Ә Ватанны саклаучылар елы якты һәм мөһим вакыйга булачак, ул әлеге нигезне саклаучыларның казанышларын ассызыклаячак. Ватанны саклаучылар елы 2025-ул календарь датасы гына түгел, ә милли бердәмлек һәм патриотизм символы. Бу яклаучыларга һәм яклауны дәвам итүчеләргә тирән рәхмәт белдерү дә.***

# Бездә күңелле

Саф һавада уеннарны балалар бик ярата.Нинди генә һава торышы булмасын, урамда алар табигатьне күзәтә, хәрәкәтле уеннар уйнап чыныга.

Балалар белән кыш көне кардан фигуралар төзү, яисә җепшек көнне кар атышлы уйнау үзе генә ни тора. Кечкенә тауычыклардан шуу, бер - береңне чанада тартып ярышу кебек уеннарныда бик яратып уйныйлар.

Кышкы уеннар балаларның физик һәм акыл сәламәтлеген саклау, спортны яратырга кызыксынучанлыкны, мөстәкыйльлекне тәрбияләү, ихтыяр көче, сабырлык, кыюлык сыйфатлары тәрбияләү, көндәлек тормышта уен вакытында башкаларга карата ягымлы мөгаләмә булдыру максатларын үтәргә ярдәм итә.







# Әти-әниләр өчен киңәшләр



***Балаларның иммунитеты нык булсын.!***
***Кыш җитү белән ата-аналар балаларының еш авыруыннан зарлана. Алар салкын тидерү,кискен сулыш юллары авырулары, вируслы инфекцияләргә күбрәк бирешә.Табиблар иммунитетны күтәрү өчен түбәндәге киңәшләрне бирә..Даруханәләрдә сатыла торган дарулардан могҗиза эзләмәгез.Бала авырмасын өчен саф һавада ешрак булырга,күбрәк хәрәкәтләнергә һә дөрес тукланырга кирәк. Бүлмәләрнең даими җилләтелеп торуы да мөһим роль уйный. .Ачык һавада вируслар бина эчендәгедән меңнәрчә тапкыр азрак.Балаларны авыру кешеләр белән аралаштырмаска тырышырга,рационга җиләк-җимешләр кертергә кирәк.Яшелчә,җиләк-җимеш, ит, йомырка, балык һәм чикләвекләр файдалы..Балаларыбызның сәламәтлеге әти-әниләр кулында,таза-сау булыйк барыбыз да!***

# *Туган телем сагында*

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар курчак театры спектакльләрен карарга бик яраталар.
Ул аларга якын, аңлаешлы. Балалар ширмада таныш һәм яраткан хәрәкәтләнүче һәм сөйләшүче, кызык курчакларын: аю, куян, песи, этне һ.б. күрәләр. Ләкин курчак театрына күңел ачу чарасы итеп кенә карарга кирәкми. Аның тәрбияви мәгънәсе бик мөһим. Мәктәпкәчә яшьтә баланың тирә-юньгә мәхәббәте, характеры, кызыксынуы формалаша башлый. Нәкъ шушы яшьтә балаларга дуслык, яхшылык, дөреслек, хезмәт сөючәнлек мисалларын күрсәтү файдалы.Безнең бакчабызда балалар үзләре дә курчаклар ярдәмендә зур булмаган спектакльләр уйнарга яраталар.
Уенга кереп китеп, алар курчакларның сорауларына җавап бирәләр,аларның сораганнарын үтиләр, киңәшләр бирәләр, теге яки бу образга керәләр.
Балада сүзлек формалаша – сүзлек яңа сүзләр белән баетыла, тулылана; бәйләнешле һәм монологик сөйләм үстерелә; сөйләмнең аваз культурасы үсә; авазларның дөрес әйтелеше эшкәртелә.Тавыш көче һәм дикция үсә. Балалар сүзләрне ачык, аңлаешлы итеп ишетелсен өчен әйтергә өйрәнәләр.Курчаклар белән уйнаганда балаларга таныш һәм аларга ошаган әкиятләрне сайлап алабыз: "Шалкан", "Теремкәй', "Йомры икмәк" һәм башкалар.



